ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 5

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 20 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 20 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

3. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2021 елның 20 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

4. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2021 елның 20 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

3. Лениногорск муниципаль районының Шөгер авыл җирлегендә

гражданнар җыенын үткәрү өчен халык исемелеген территориаль билгеләр буенча бүлү тәртибен билгеләргә.

4.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән (дүрт һәм аннан күбрәк бала), Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту
- Урамнарны яктыртуны оештыру
- Җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17, балалар бакчасы, Киров ур., 23, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин ур., 32, Шөгер авыл мәдәният йорты, Ленин ур., 35, Шөгер 3 участок хастаханәсе, Горький ур., 4 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Р.Н.Гафиятуллин